УДК 929

# ГАЛИМӘ ХӘКИМОВА РАБИГА АФЗАЛОВНА: ТОРМЫШ ЮЛЫ ҺӘМ ЭШЧӘНЛЕГЕ

***Х.З. Баһаветдинова***

*Татарстан Фәннәр академиясенең*
*Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*halida12_61@mail.ru*

Мәкаләдә күренекле татар теле белгече, доцент, Казан дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеген оештырган Хәкимова Рабига Афзаловнаның тормыш юлы һәм фәнни-педагогик эшчәнлеге өйрәнелә. Р.А. Хәкимова – авыл укытучысыннан университет доценты дәрәҗәсенә ирешкән галимә. Хезмәте өчен хөкүмәт тарафыннан медальләр, почет билгеләре белән бүләкләнгән. Немец, рус, башкорт һәм татар телләрен яхшы белгән, казах, кыргыз телләрендә дә аралаша алган. Мәскәүдә СССР Фәннәр академиясенең Тел, СССР халыкларының язма мирасын өйрәнү институтының аспирантурасын тәмамлап, кандидатлык диссертациясен яклаган. Мәкаләдә галимәнең басылып чыккан кайбер фәнни хезмәтләренең исемлеге дә китерелә.

Хәкимова Рабига Афзаловна партия эшләрендә дә актив катнашкан галимә, шуның аркасында, аңа шелтәләр дә алырга туры килә. Бу хәлләр лаеклы, бәхетле гаилә кору мөмкинлегенә дә киртә булып баса.

Шулай ук мәкаләдә 1944–1951 еллар арасында татар теле һәм әдәбияты кафедрасының эшчәнлегенә дә анализ ясала. Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге китапханәсендә саклanган, профессор Хатыйп Госманның “Формирование новой специальности” дигән хезмәтеннән өзек китерелә. Бу чорларда эшләгән укытучылар, белем алган студентлар турында да мәгълүмат бирелә.

1951 елның 9 маенда Р.А. Хәкимова авыру сәбәпле эшеннән азат ителә. Ни кызганыч, тормыш юлында очраган каршылыкларны җиңү эзсез калмаган, күрәсең. Күренекле галимәбезнең сәламәтлеге нык какшый, бу аның вакытсыз үлеменә сәбәп була.

**Төп төшенчәләр:** Хәкимова Рабига Афзаловна, автобиография, татар теле һәм әдәбият бүлеге

**Сылтама ясау өчен:** Баһаветдинова Х.З. Галимә Хәкимова Рабига Афзаловна: тормыш юлы һәм эшчәнлеге // Историческая этнология. 2021. Т. 6, №. 1. С. 132–140. https://doi.org/10.22378/he.2021-6-1.132-140

Халкыбыз мәгарифенең тарихына күз салсак, анда гомерләре бик кыска, әмма кылган гамәлләре белән һич онытылмаска тиешле гүзәл шәхесләребез бар. Чистай өязе Краснояр волосте (Татарстанның хәзерге

Чистай районы) Кутлушкино (Яуширмә) авылында туып үскән Рабига Хәкимова шуларның берсе. Гаиләдә әтисе Афзал ага да, әнисе Хәдичә ханым да милләтебезнең бөтен гореф-гадәтләрен хөрмәтләп, намуслы хезмәт итеп яшәгән игенчеләр булганнар.

Рабиганың мәгарифкә багышланган хәерле гомере 15 яшеннән балалар укыту белән башланып китә. Туган авылы мәктәбен тәмамлау белән ул Чистай кантонының Иске Татар Әдәмсуы, Әлки, Каргалы, Мөслим, Чистай, Кизләү (Курманаево) авылларының беренче баскыч мәктәпләрендә укыта (ТР ДА Р-1137: 22).

1920 еллар уртасы – сугышлар тәмамланган, әкренләп ачлык афәтеннән дә котыла башлаган чор. Ил, ниһаять, тыныч төзелешкә, ягъни халык хуҗалыгын торгызуга керешә. Бу үзгәрешләргә хатын-кызларны тарту өчен максатлы эш җәелдерелә. Хатын-кызлар арасында эшләү өчен партия иң уңган алдынгы карашлы укытучыларны тарта. Рабига да шулар арасында була: Иске Әлмәт, Зур Тигәнәле авылларында хатын-кызлар оешмаларын җитәкли. Тырыш хезмәте өчен аны 1928 елда Бөтенсоюз коммунистлар партиясе сафларына кабул итәләр һәм, партия әгъзасы буларак, аңа тагын да җаваплырак эшләр тапшыралар.

Шушы ук елда ул Казанга күчеп килә һәм 5 номерлы тегү фабрикасына эшкә урнаша. Биредә дә Рабига җәмәгать эшләрендә актив катнаша, цех профсоюз бюросының рәисе, соңрак фабрика коммунистлар партия оешмасының җаваплы секретаре вазифаларын үти.

Хәкимова Рабига Афзаловнаның шәхси тормышына бәйле документлар, истәлекләр юк диярлек. Татарстан Республикасы милли архивында сакланган, 1930 елның 14 июнендә язган аңлатмасыннан, 1928 елда Баһаутдин исемле укытучы егеткә кияүгә чыгып, 3 ай яшәгәч, аерылышулары аңлашыла (ТР ДА П-1198: 4–4об.). Икенче тапкыр 1930 елда Шәрәфетдинов Минһаҗ (1898) белән тормыш кора. Аның белән дә кулак малае булганга аерылырга туры килә (ТР ДА Р-1137: 14). Ис китәрлек хәл, ике очракта да Рабига Афзаловнага партия тарафыннан шелтә белдерелгән. Моның өстәвенә, 1936 елда репрессияләнгән авторларның псевдоним астында чыккан материалларына рөхсәт имзасын куйган өчен Молотов райкомыннан каты шелтә алганлыгы билгеле (ТР ДА Р-1137: 5). Бу гаделсезлекләр, шелтәләр алу аның шәхси тормышына да тәэсир итми калмаган, күрәсең. Рабига Афзаловна, дөреслекне яклап, югары оешмаларга мөрәҗәгать итә. Бу «ха-



Рабига Афзаловна Хәкимова.
Татарстан Республикасы
Дәүләт архивы. Ф. Р-1137.
Т. 31. Эш 190. 2 б.

таларны» тәҗрибәсезлектән, белеме аз булу белән аңлата һәм, ниһаять, 1940 елда бирелгән шелтәләрне кире алалар.

Бу вакыйгалардан соң ул кияүгә чыкмый, әти-әниләрен югалткан бертуганнарының кызларын тәрбиягә ала. Зарә Рабига ханым белән яши. Казан шәһәренең 11 номерлы мәктәбен тәмамлый.

Рабига Хакимованың бертуган 2 сеңлесе, 2 энесе була: Хәнифә (1906) – ире Гәлимов белән Юхмачы районында җитәкче урыннарда эшлиләр, партия әгъзалары; Сафия (1918) Казанда ТЭЦ-2 дә эшли, Бөек Ватан сугышында катнаша. Шулай ук ике энесе дә Бөек Ватан сугышында катнашалар: сугыштан соң Әгъләм (1910) авылда колхозчы, Камал (1913) партия әгъзасы, Чистайда яши һәм эшли.

Рабига 1930–1932 елларда Татар коммунистлар университетында 2 ел белем ала. Бер үк вакытта райкомда инспектор булып эшли. 1932 елдан Казан Педагогика институтына укырга керә. 1933 елда Партия Үзәк комитеты карары белән Сарман МТСы сәяси бүлекчәсенә эшкә җибәрелә. 1935–1936 елларда Татарстан радиокомитетның сәяси редакторы булып тора. 1936–1940 елларда Педагогика институтында укуын дәвам итә. Шул ук елларда Казан шәһәренең 80 нче номерлы мәктәбендә укытучы булып та эшли.

1940 елда институтны тәмамлагач, Рабига Мәскәү шәһәрендәге СССР Фәннәр академиясенең Тел, СССР халыкларының язма мирасын өйрәнү институтының (соңыннан бу институт академик Марр исемендәге Тел һәм фикерләү институты дип үзгәртелә) аспирантурасына укырга керә. 1944 елның 30 июнендә Мәскәүдә «Глагольное управление в современном литературном языке» темасына кандидатлык диссертациясен яклый һәм филология фәннәре кандидаты дигән фәнни дәрәҗәгә ия була (ТР ДА Р-1137: 6).

1944 елның октябрь аеннан В.И. Ульянов исемендәге Казан дәүләт университетында укыта башлый. Бер ай узу белән, Хәкимова Рабига Афзаловнага университетның Гыйльми советы, доцент һәм кафедра мөдире вазифаларын йөклиләр. Тавыш бирү нәтиҗәләре: 24 – әйе, 3 се – тыелып кала (ТР ДА Р-1137: 23).

1804 елда ачылган Казан университеты тарихында беренче тапкыр һәм Рабига Афзал кызы тырышлыгы белән 1944 елда Татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачыла. Биредә филолог-галимнәр, киң профильле гуманитар белгечләр, шулай ук татар теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләнә башлый.

Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә профессор Х. Госмановның «Формирование новой специальности» дигән кулъязмасы саклана (Усманов: 1). Язмада университетта татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылу һәм аның үсеш баскычлары тарихы тасвирлана. Түбәндә кулъязмадан өзек китерәбез (тәрҗемә. – *Х.Б.*): «Авыр вакытлар иде. Сугыш һаман дәвам итә. Бүлекне оештыру доцент Рабига Афзаловна Хәкимовага тапшырылды. Аның оештыру тәҗрибәсе бар иде, ул тиз арада, яңа уку елы башына I курска студентлар кабул итәргә иреште. Әмма иң авыры – уку процессын җайга салу булды. Барыннан да элек кадрлар юк иде. Профессор М. Корбангалиев сугыш башланыр алдыннан вафат

булды. Алар (галимнәр. – *Х.Б.*) Казанның башка уку һәм фәнни учреждениеләрендә дә бик аз калган иделәр. Күбесе сугышка китте, бик азлары гына кире кайтты. Университетта бүлек ачылган вакытта, бөтен Казанга татар филологиясе фәнендә 2–3 кандидат исәпләнә, докторлар турында әйтеп тә торасы юк. Кафедра эшенә керешү өчен 4 штат берәмлеге бүлеп бирелде: мөдир, гәрәп теле белгече һәм 2 лаборант. Алар арасында, бары мөдирнең генә кандидатлык гыйльми дәрәҗәсе була.

Бүлекне зурайту нәтиҗәсендә уку-укыту эшенең профиле тагын да артты. Бу очракта күптән түгел генә ачылган СССР ФА Казан филиалы белгечләрен ярты ставкага һәм сәгатьләп (почасовой) укытырга чакыру файдага булды. Аларның да гыйльми дәрәҗәләре юк иде. Кыенлыкларга карамастан, 1950 елда татар теле һәм әдәбияты белгечләренең беренче чыгарылышы була.

Кафедра җитәкчесе Р.А. Хәкимова озакка авырып китте (1952 елда вафат булды). 1951 елның җәендә мөдир итеп мине сайладылар[1]. ...

Гомумән алганда, бүлекнең ни хәлдә калганын түбәндә язып узам. Барыннан да элек, кафедраның теге яки бу уку йөкләмәләрен үтәү белән бәйле көчләрнең берләшүе җитмәде. Түбәндә күрсәтелгән даими составтагы дүрт заттан тыш, ярты ставкага һәм сәгатьләп укытучылар чакырылган. Алар арасында Латиф Җәләй, әдәби тәнкыйтьче Гази Кашшаф кебек җитди кешеләр бар иде. Тиздән Педагогика институтыннан бу өлкәдә тәҗрибәсе булган оста педагог, филология фәннәре кандидаты Якуб Хәлил улы Агишев килде. Моннан тыш, Хакимова тырышлыгы белән, бүлекнең беренче чыгарылышыннан калган тагын өч аспирант та бар иде (Усманов: 1)».

Абитуриентларны укырга алганда ук, укытучылар аларның белем дәрәҗәсенә генә түгел, иҗади мөмкинлекләренә дә игътибар итәләр. Бүлек каршында әдәби түгәрәк һәм агитбригада эшли, «Әдәби сүз» дип аталган кульязма газета чыга башлый (Замалетдинов, Хабутдинова 2018: 103). Бу чараларның барлыкка килүе, Рабига Афзаловнаның оештыру сәләте югары булуын дәлилли торган фактлар.

Кафедрада Рабига Афзаловна оештыру һәм методик эшләрне, уку планнарын һәм программалар төзү, фәнни хезмәткәрләр туплау, студентлар кабул итү, тәрбия эшләрен алып бара. Үзе немец, рус, башкорт һәм татар телләрен яхшы белә. Шулай ук казакъ, кыргыз телләрендә дә аралаша ала. Конференцияләрдә югары дәрәҗәдә фәнни чыгышлар ясый. 1947 елда

---

[1] 1947 елда Р.А. Хәкимова тарих-филология факультеты деканы, проф. Вознесенский исеменә мөдирлектән азат итүне сорап гариза (докладной) яза. Үз урынына филология фәннәре кандидаты, әдәбият галиме Я.Х. Агишевны эшкә алуларын сорый. Аңа уңай характеристика бирә (ТР ДА Р-1137:45–45об.). Күрәсең, Рабига Афзаловнаны мөдирлектән азат итмәгәннәр. Бары тик, җитди авыруы сәбәпле, 1951 елның 16 февраленнән бүлек мөдире вазифаларын М.Х. Гайнуллин башкарган (ТР ДА Р-1137: 81). Уку елы тәмамлангач, мөдир итеп Хатиб Госмановны сайлаганнар.

СССР Фәннәр академиясе Тел һәм фикерләү институтының 25 еллык юбилее уңаеннан узган 3 көнлек фәнни сессиядә катнаша (ТР ДА Р-1137: 43).

Рабига Афзаловна университет тарафыннан оештырылган диалектологик экспедицияләрнең җитәкчесе була (ТР ДА Р-1137: 47). 1948 елда мишәрләр һәм аларның телен өйрәнүгә багышланган зур экспедиция оештырыла. Төркемгә җитәкче иң яхшы дип саналган студентларны – Фәсиев, Хафизова, Кәримова, Галимҗанова (3 курс), Сабирова (1 курс), Маннапова, Габдрахимоваларны (2 курс) сайлап ала. Фән ягыннан бик кирәкле, кызыклы булган материаллар җыеп кайталар. Рабига Афзаловна, студентлар яхшы эшләгәннәре өчен аларга рәхмәт белдерүләрен сорап, ректор К.П. Ситниковка гариза яза, студентларны һәрвакыт кайгыртып яши (ТР ДА Р-1137: 65).

Икенче бер мисал, язучы Аяз Гыйләҗев истәлекләреннән: «...Азыктөлек юнәтер әмәлне белмибез, сала кабартмалары, шыр тилеләр... Кафедра мөдиребез Н.Я. Марр шәкерте Рабига Афзаловна гына күңелне күтәрә» (Замалетдинов, Хабутдинова 2018: 104).

Күренекле шәхесләр – филология фәннәре кандидаты, тел белеме галиме Фазыл Салих улы Фәсиев (1925–2016), филология фәннәре докторы, профессор, язучы Ибраһим Зиннәт улы Нуруллин (1923–1995), филология фәннәре кандидаты, татар әдәбияты белгече Рашат Габдерәшит улы Гайнанов (1925–1990), язучы Аяз Мирсәет улы Гыйләҗев (1928–2002) һ.б. – Рабига Афзаловна шәкертләре.

Хәкимова Рабига Авзалованың фәнни-педагогик эшчәнлегенең төп юнәлеше – татар телен укыту мәсьәләләре. Ул докторлык диссертациясе өстендә дә эшли, тикшеренүләр алып бара. Хәтта үз хисабына Мәскәүгә командировкаларга йөри. Ләкин, авыру сәбәпле, фәнни хезмәтен тәмамлый алмый (ТР ДА Р-1137: 62). Басылып чыккан фәнни хезмәтләреннән: «Татар теле орфографиясе сүзлеге» (1940); «Каюм Насыров как лингвист» (1947), «Н.Я. Марр и новое учение о языке» (1949), «Тел белән аң, эчтәлек белән форма арасындагы бәйләнеш» (Совет мәктәбе, 1949); «Тел гыйлеменең яңа баскычында» мәкаләләрен атап үтик.

«Кызыл Татарстан» газетасында 1951 елда басылып чыккан «Тел гыйлеменең яңа баскычында» мәкаләсендә Рабига Хәкимова болай дип яза (тәрҗемә. – *Х.Б.*): «...Филология көчләре зур проблемаларны һәм мәсьәләләрне җентекле өйрәнү һәм хәл итү тирәсенә тупланмаган, һәркем, үз оешмасы, үз кабыгына бикләнеп эш итә, берсе нәрсә эшләгәнне икенчесе белми, педагогия институты һәм университет филологлары укыту эшләре белән фәнни-тикшеренү эшләрен бергә бәйләп алып баруны тиешле дәрәҗәдә оештыра алганнары юк әле. Фәнни-тикшеренү эшләренә җитәкчелек итәргә һәм гомумиләштерелгән теоретик гыйльми хезмәт үрнәкләре бирергә тиешле булган Тел, әдәбият һәм тарих институты исә фәнни көчләрнең һәм учреждениеләрнең энергиясен туплауга искиткеч ваемсызлык күрсәтеп килә, әйдәүчелек ролен уйнамый, тел һәм әдәбият фәннәре өлкәсендәге фәнни эшләрне ... үзгәртеп кору үрнәкләрен күрсәтми» (Миң-

нуллин 2016: 153–154). Мәкаләдә китерелгән фикерләр бүгенге көндә дә актуаль дип әйтсәк, ялгышмабыз дип уйлыйм.

Рабига ханым 16 ел дәвамында укытучы булып хезмәт итә. Университетның Тарих-филология факультетының җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Татар бүлегендә укыту-тәрбия бирү эше белән җитәкчелек итә. Уку төркеменең агитаторы. Казан шәһәренең күп кенә оешмаларында туган телендә чыгышлар ясый (Усманов: 80).

Рабига Хәкимова – күп кенә Дәүләт бүләкләренә ия шәхес: 1941 елда Мәскәүне саклауда катнашканы өчен СССРның Югары Совет указы нигезендә «Мәскәүне саклау» медале (Усманов: 9), кадрлар әзерләүдә актив катнашканы өчен «Почет билгесе» ордены, күп санлы рәхмәт хатлары белән бүләкләнә (1945, 1948, 1950).

1951 елның 9 маенда Р.А. Хәкимова, авыру сәбәпле (2 группа инвалид), эшеннән азат ителә. 1952 елда вафат була.

Рабига ханым – авыр, кырыс елларда яшәп, милләтебезгә тугры хезмәт итә алган шәхес. Бергә укыган, эшләгән дусларының, сабакташларының күбесен репрессия еллары йоткан. Нечкә күңелле хатын-кызга бу борчулар тәэсир итми калмагандыр. Без бүген аның кичерешләрен аңлап, тормышына сокланабыз.

## ЧЫГАНАКЛАР

ТР ДА Р-1137 – Татарстан Республикасы Дәүләт архивы. Ф. Р-1137. Т. 31. Эш 190.

ТР ДА П-1198 – Татарстан Республикасы Дәүләт архивы. Ф. П-1198. Т. 1. Эш 2804.

Усманов – Усманов Х.У. Формирование новой специальности // КФУ НБЛ ОРРК. Ед. хр. 100681/1. Рукопись.

## ФӘННИ ӘДӘБИЯТ

Замалетдинов Р.Р., Хабутдинова М.М. История создания отделения татарского языка и литературы в Казанском университете в воспоминаниях преподавателей и первых студентов // Tatarica. 2018. №1 (10). С. 91–112.

Миңнуллин Ф.Г. Тел гыйлеменең яңа баскычында // Татар педагогик фикере антологиясе. 2 т. (XX гасыр – XXI гасыр башы). Казан: Татар. китап. нәшр., 2016.

**Автор турында белешмә:** Баһаветдинова Халидә Зиннатовна – фәнни хезмәткәр, Татарстан халыкларының тарихи-мәдәни мирасы бүлеге, Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты (420111, Батурин урамы, 7А, Казан, Россия Федерациясе); halida12_61@mail.ru

*Редакциягә керде 22.09.2020* *Кабул ителде 22.03.2021*
*Басылды 21.04.2021*

# SCHOLAR RABIGA AFZALOVNA KHAKIMOVA: ACADEMIC WORK AND LIFE PATH

***Kh.Z. Bagautdinova***

*Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*halida12_61@mail.ru*

The article highlights the life and scientific and pedagogical work of the outstanding Tatar linguist, associate professor, founder of the department of the Tatar Language and Literature of Kazan State University, Khakimova Rabiga Afzalovna. R.A. Khakimova worked her way up from a rural teacher to an associate professor at university. For many years of work she was awarded with medals and signs of honour. She knew German, Russian, Bashkir and Tatar languages well, as well as she could also communicate in Kazakh and Kyrgyz. R.A. Khakimova completed her postgraduate studies at the Institute of Linguistics of the USSR Academy of Sciences in Moscow and defended her Ph.D. thesis. The article provides a list of some of the published academic works of the scholar. Khakimova Rabiga Afzalovna was actively involved in the political work, due to which she had to receive reprimands. All of that became an obstacle to a happy family life.

The article also analyzes the work of the Tatar Language and Literature Department in the period from 1944 to 1951. An excerpt from the work of Professor Khatip Guzman "Formation of a new specialty", which has been kept in the N.I. Lobachevsky library of Kazan University, provides information about the teachers who worked during those years, as well as about the students.

On May 9, 1951 R.A. Khakimova was dismissed for health grounds. Unfortunately, the obstacles that arose in the scholar's life left their mark: Rabiga Afzalovna's health deteriorated dramatically, which caused her sudden death.

**Keywords:** Khakimova Rabiga Afzalovna, autobiography, department of the Tatar language and literature

**For citation:** Bagautdinova Kh.Z. Galimä Häkimova Rabiga Afzalovna: tormysh yuly häm eshchänlege [Scholar Rabiga Afzalovna Khakimova: Academic Work and Life Path]. *Istoricheskaya etnologiya*, 2021, vol. 6, no. 1, pp. 132–140. https://doi.org/10.22378/he.2021-6-1.132-140

## REFERENCES

Zamaletdinov R.R., Khabutdinova M.M. Istoriya sozdaniya otdeleniya tatarskogo yazyka i literatury v Kazanskom universitete v vospominaniyakh prepodavateley i pervykh studentov [The History of Founding the Tatar language and Literature Department at Kazan University in the Memoirs of Teachers and First Students]. *Tatarica,* 2018, №1 (10), pp. 91–112.

Minnullin F.G. Tel gyylemenen yana baskychynda [At a New Stage of Philology] // *Tatar pedagogik fikere antologiyase. 2 t. (XX gasyr – XXI gasyr bashy).* Kazan: Tatar Book Publ., 2016.

**About the author:** Khalida Z. Bagautdinova, Research Fellow, Department of Historical and Cultural Heritage of the Peoples of Tatarstan, Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7A Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); halida12_61@mail.ru

*Received September 22, 2020* *Accepted for publication March 22, 2021*
*Published April 21, 2021*

## УЧЕНЫЙ ХАКИМОВА РАБИГА АФЗАЛОВНА: НАУЧНАЯ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ И ЖИЗНЕННЫЙ ПУТЬ

***Х.З. Багаутдинова***

*Институт истории им. Ш. Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*halida12_61@mail.ru*

В статье освещаются жизнь и научно-педагогическая деятельность выдающегося татарского языковеда, доцента, основателя отделения татарского языка и литературы Казанского государственного университета Хакимовой Рабиги Афзаловны. Р.А. Хакимова прошла путь от сельского учителя до доцента университета. За многолетний труд награждена медалями, знаками почета. Она хорошо знала немецкий, русский, башкирский и татарский языки, могла также изъясняться на казахском и киргизском языках. Р.А. Хакимова окончила аспирантуру Института языкознания Академии наук СССР в Москве, защитила кандидатскую диссертацию. В статье приводится список некоторых опубликованных научных трудов ученой. Хакимова Рабига Афзаловна активно участвовала и в партийной работе, из-за чего ей приходилось получать выговоры. Все это стало препятствием для счастливой семейной жизни.

Также в статье анализируется деятельность кафедры татарского языка и литературы в период с 1944 по 1951 гг. Приводится отрывок из труда профессора Хатипа Гусмана «Формирование новой специальности», хранящегося в библиотеке им. Н.И. Лобачевского Казанского федерального университета. Приводятся сведения о преподавателях, работавших в эти годы, а также о студентах.

9 мая 1951 г. Р.А. Хакимова была уволена по состоянию здоровья. К сожалению, препятствия, возникшие на жизненном пути ученой, оставили свой след: здоровье Рабиги Афзаловны сильно пошатнулось, что стало причиной ее скоропостижной смерти.

**Ключевые слова:** Хакимова Рабига Афзаловна, автобиография, кафедра татарского языка и литературы

**Для цитирования:** Баһаветдинова Х.З. Галимә Хәкимова Рабига Афзаловна: тормыш юлы һәм эшчәнлеге // Историческая этнология. 2021. Т. 6, №. 1. С. 132–140. https://doi.org/10.22378/he.2021-6-1.132-140

**Сведения об авторе:** Багаутдинова Халида Зиннатовна – научный сотрудник отдела историко-культурного наследия народов Республики Татарстан Института истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан (420111, ул. Батурина, 7А, Казань, Российская Федерация); halida12_61@mail.ru

*Поступила 22.09.2020* *Принята к публикации 22.03.2021*
*Опубликована 21.04.2021*